УРАЗА
Уразаның максаты
→ 4-5 БИТ

ВӘГАЗЬ
Рамазан ункөнлекләренең хикмәте
→ 6 БИТ

НӘСЫЙХӘТ
Гамәлләргә рия керү
→ 12 БИТ

ТӘРБИЯ
Замана кешесенә нәрсә җитми?
→ 13 БИТ



**МАРТ, 2023**
№ 03 (332)

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы

ШӘГЪБАН-РАМАЗАН, 1444


# دين و معيشت

# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

12+




Фото: shutterstock.com

ГАЗЕТАДА АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ ИСЕМНӘРЕ, КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ БУЛГАНЛЫКТАН, БАСМАГА ИГЪТИБАРЛЫ БУЛЫГЫЗ!

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 03 (332) март, 2023 | шәгъбан - Рамазан, 1444

# Казанда ифтарлар кайда узачак?

**Сезнең игътибарга башкалабыз Казанда ифтарлар уздырыла торган мәчетләр исемлеген тәкъдим итәбез. Әлеге мәҗлесләргә теләге булган һәркем барып авыз ача ала. Ифтарлар Казанда гына да 42 мәчеттә узачак. Моннан тыш, кайбер мәчетләр, пандемия чорында башланган традицияне дәвам итеп, ифтарга ланч-бокслар таратуны оештыра.**

Шунысы игътибарга лаек: ифтар мәҗлесләрен үз исемеңнән оештырырга мөмкин, чөнки изге Рамазан аенда ураза тотучыларны һәм мохтаҗларны ашаткан өчен Аллаһы Тәгалә зур әҗер-савап бирә. Сөекле Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисендә: «Кем дә кем ураза тотучыны ашатса, аңа ураза тотучының әҗер-савабыннан киметелмичә әҗер-савап булачак», – дип хәбәр ителә. Авыз ачу мәҗлесләрен үз исемеңнән оештыру өчен, түбәндә күрсәтелгән мәчетләрнең имамнарына мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Ифтарлар уза торган мәчетләр исемлеге тулылана ала.

### КАЗАН ШӘҺӘРЕ ВАХИТОВ ҺӘМ ИДЕЛ БУЕ РАЙОНЫ МӨХТӘСИБӘТЕ (КӨН САЕН):

| | |
|---|---|
| «Галиев» | Г.Тукай ур, 40 йорт |
| «Гадел» | Казан ш., Оренбург проезды, 193 йорт |
| «Әл-Мәрҗани» Җәмигъ мәчете | Казан ш., Каюм Насыйри урамы, 17 йорт |
| «Туган авылым» | Казан ш., Туфан Миңнуллин урамы, 14 йорт |
| «Хәдичә» | Казан ш., Тынычлык урамы, 3 йорт |
| «Өмет» | Казан ш., Дачная урамы, 3а йорты |
| «Тынычлык» | Казан ш., Мелитопольская урамы, 15 йорт |
| «Ал» | Казан ш., Мәҗит Гафури урамы, 67 йорт |
| «Хөзәйфа» | Казан ш., Юлиус Фучик урамы, 52 йорт, 1 к. |
| «Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемен-дәге Кабан арты мәчете» | Казан ш., Һади Такташ урамы, 26 йорт |

### ИФТАР-БОКСЛАР КАЙДА ТАРАТЫЛАЧАК:

| | |
|---|---|
| «Ризван» | Казан ш., Хөсәен Мәүлетов урамы, 48а йорты |




Фото: dumrt.ru

### КАЗАН ШӘҺӘРЕНЕҢ СОВЕТ РАЙОНЫ МӨХТӘСИБӘТЕ (КӨН САЕН):

| | |
|---|---|
| «Бистә Нуры Габделгалләм» | Казан ш., Пионерская урамы, 5 йорт |
| «Гаилә» | Казан ш., Җәүдәт Фәйзи урамы, 2 йорт |
| «Ислам» | Казан ш., Вяземская урамы, 28 йорт |
| «Иман нуры» | Казан ш., Дорожная урамы, 32а йорты, 1 к. |
| «Әхтәм» | Казан ш., Мирсәй Әмир урамы, 15 йорт |
| «Вәлидәйн» | Казан ш., Тамчы урамы, 42 йорт |
| «Ярулла» | Казан ш., Нокса урамы, 32д йорты |
| «Коддус» | Казан ш., Яснополянский тыкрыгы, 16 йорты |

### МӨМКИНЛЕККӘ КАРАП, ИКЕ КӨНГӘ БЕР, ӨЧ КӨНГӘ БЕР ТАПКЫР ҮТКӘРӘЛӘР:

| | |
|---|---|
| «Ибраһим» | Казан ш., Локаторная урамы, 33б йорты |
| «Саләх» | Казан ш., Мамадыш тракты урамы, 18 йорт |
| «Шәрәфетдин» | Казан ш., Ягодная урамы, 6д йорты |
| «Мөслимә» | Казан ш., ул. 1 нче Нокса урамы, 31 йорт |
| «Дин Ислам» | Казан ш., Чишмәле урамы, 17а йорты |

### КАЗАН ШӘҺӘРЕ КИРОВ ҺӘМ МӘСКӘҮ РАЙОНЫ МӨХТӘСИБӘТЕ (КӨН САЕН УЗА ТОРГАН ТРАДИЦИОН ИФТАРЛАР):

| | |
|---|---|
| «Ярдәм» | Казан ш., Серов урамы, 4а йорты |
| «Мәүлид» | Залесный бистәсе, Селянская урамы, 23 йорт |
| «Миргазиян» | Казан ш., Декабристлар урамы, 111 йорт |
| «Рамис» | Яңа Юдино бистәсе, Яңа Юдино урамы, 140 йорт, 2 к. |

| | |
|---|---|
| «Рамазан» | Казан ш., Окольная урамы, 256 йорты |
| «Әл-Ислах» | Осиново бистәсе, Комсомольская урамы, 66 йорты |
| «Бишбалта» | Казан ш., Клара Цеткин урамы, 14 йорт |
| «Рәҗәб» | Казан ш., Энгельс урамы, 20/39 йорты |
| «Ай нуры» | Казан ш., ул. Академик Королев урамы, 2 йорт |
| Әхмәдзәки хәзрәт Сафиуллин исемендәге мәчет | Казан ш., Осиновский тыкрыгы, 16а йорты |

**«ЯРДӘМ - ПОМОЩЬ» ГОМУММИЛЛИ ХӘЙРИЯ ФОНДЫ КӨН САЕН БУ МӘЧЕТЛӘРДӘ ИФТАР ӨЧЕН ЛАНЧ-БОКСЛАР ТАРАТАЧАК:**

| | |
|---|---|
| «Ярдәм» | Казан ш., Серов урамы, 4а йорты |
| «Рамазан» | Казан ш., Окольная урамы, 256 йорты |
| «Рәҗәб» | Казан ш., Энгельс урамы, 20/39 йорты |
| «Ай Нуры» | Казан ш., Ак.Королев урамы, 2 йорт |
| «Әл-Ислах» | Осиново бистәсе, Комсомольская урамы, 66 йорты |
| «Мәүлид» | Залесный бистәсе, Селянская урамы, 23 йорт |
| «Рамис» | Яңа Юдино бистәсе, Яңа Юдино урамы, 140 йорт, 2 к. |
| «Миргазиян» | Казан ш., Декабристлар урамы, 111 йорт |
| «Бишбалта» | Казан ш., Клара Цеткин урамы, 14 йорт |
| «Азатдин Ирек» | Казан ш., Лагерьная, 111 йорт |

**КАЗАН ШӘҺӘРЕ АВИАТӨЗЕЛЕШ ҺӘМ ЯҢА САВИН РАЙОНЫ МӨХТӘСИБӘТЕ (КӨН САЕН):**

| | |
|---|---|
| «Нур Әл-Ислам» | Казан ш., Бигиев урамы, 36 йорт |
| «Салихҗан» | Казан ш., Бестужев урамы, 66а йорты |
| «Рәхмәтулла» | Казан ш., Симонов урамы, 2 йорт |

**МӨМКИНЛЕККӘ КАРАП, ИКЕ КӨНГӘ БЕР, ӨЧ КӨНГӘ БЕР ТАПКЫР ҮТКӘРӘЛӘР:**

| | |
|---|---|
| «Фатиха» | Кадыш бистәсе, Рихард Зорге урамы, 2а йорты |
| «Кыйбла» | Щербаково бистәсе, Молодежная урамы, 1а йорты |
| «Өмет» | Борисоглебск бистәсе, Школьная урамы, 4а йорты |

**Хөрмәтле дин кардәшләребез! Җөмһүриятебез районнарының мәчетләрендә ифтар уздыру урыннары белән ТР Диния нәзарәте сайты (dumrt.ru) аша таныша аласыз.**

**dumrt.ru** сайтыннан



Фото: dumrt.ru

# Нәзарәт сайтында «Рамазан-2023: төп сораулар» сәхифәсе эшли башлады

**Рамазан-шәриф алдыннан Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте сайтының «Файдалы мәгълүмат» бүлегендә «Рамазан-2023: төп сораулар» сәхифәсе эшли башлады.**

Ул сайт файдаланучыларга изге айны үткәрү, ураза тоту һәм башка дини йолаларның тәртипләренә кагылышлы иң киң таралган сорауларга кирәкле һәм нигезле җаваплар табу мөмкинлеген бирә.

Аерым алганда, әлеге сәхифәдә ураза башлану һәм тәмамлану, тәравих намазын уку вакыты һәм тәртибе, 2023 елда Рамазан аенда фитр садакасы, фидия һәм нисаб күләме, Ураза бәйрәмен билгеләү һәм башка мәсьәләләр буенча актуаль мәгълүмат урнаштырылган.

Сәхифә Рамазан ае дәвамында эшләячәк һәм яңа материаллар белән тулыландырылып торачак.

**dumrt.ru** сайтыннан

# Галиев мәчетендә Коръән хәтем кылына башланды



Фото: dumrt.ru

Рамазан-шәриф аеның 1 нче көнендә Казанның Галиев мәчетендә Коръән хәтем кылына башлады. Хафиз, Галиев мәчете мөәзине Нурмөхәммәд хәзрәт Исламов көн саен өйлә намазыннан соң (сәгать 12.00 дән соң) бер җөзне, ягъни Коръәннең 1/30 өлешен укып чыгачак. Хәтем кылу Рамазан аеның соңгы көнендә тәгалләнәчәк. Коръәнне хәтем кылуга һәркем кушыла ала: Галиев мәчетеннән Нәзарәтнең «ДУМ РТ» телеграмм-каналында аның турыдан-туры трансляциясе алып барыла.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Коръәннән бер аять тыңлаучыга икеләтелгән савап язылачак, ә Коръән укучыга Кыямәт көнендә нур бүләк ителәчәк», – дигән.

**dumrt.ru** сайтыннан

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 03 (332) март, 2023 | шәгъбан - Рамазан, 1444

# УРАЗАНЫҢ МАКСАТЫ

**Мөбарәк Рамазан аена аяк бастык. Бу ай – ураза ае. Ел дәвамында сагынып көтеп алган ураза безгә нәрсә бирә соң? Әлеге гамәл-гыйбадәтнең үзенчәлеге нидә? Шулар хакында фикерлик әле.**

Мөселман кешесе иртәдән кичкә кадәр ашамыйча-эчмичә, җенси теләкләрен тыеп, уразасын фарыз шартларга туры килерлек итеп тота ала, ләкин барыбер уразадан көтелгән файдага ирешмәскә мөмкин.

Беренче чиратта шуны әйтү мөһим: Аллаһы Тәгалә әмер иткәнлектән, без уразаны Аның ризалыгы өчен тотабыз. Шул ук вакытта, әлеге әмерне үтәгәндә нindидер файдага да ирешәбез, чөнки, Аллаһы Тәгалә безгә ни генә әмер итсә дә, аларның барысында да безнең өчен дөньяви вә рухи файда бар. Дөреслектә, безнең аларны кылу яки кылмавыбыздан Аллаһы бернинди файда да, зыян да күрми. Гомумән, безнең ач торуыбыз Аллаһыга кирәкми. Аллаһы галәмдәге бер нәрсәгә дә, бер мәхлүкъка да мохтаҗ түгел.

***Аллаһы Тәгалә Үзенең әмерләрен колларына золым, авырлык һәм кыенлык теләп бирмәгән. Раббыбыз болай дип әйтә: «Аллаһы галәмнәргә золым теләми».***

*«Әлү Гыйммран / Гыйммран гаиләсе», 3:108*

Димәк, Аллаһы Тәгалә безгә ни генә әмер итсә дә, алар барысы да безне матди вә рухи яктан камилләштерү өчен әмер ителгән. Әмма без бары Аллаһы Тәгалә кушканлыктан һәм Аның ризалыгын алыр өчен генә гыйбадәт кылабыз. Мондый зур мөмкинлекләр биргәне өчен, Аллаһы Тәгаләгә шөкер итсәк иде.

Аллаһы ризалыгы өчен тоткан уразабыз матди вә рухи яктан файдалы булсын өчен нәрсәгә игътибар итәргә кирәк соң? Бу хакта Ислам диненең бөек галиме вә күренекле фикер иясе имам Әл-Газали «Ихйә гыйлемед-дин» исемле китабында язып калдырган. Ислам динен яхшы белгән һәм Аллаһы кушканча яшәргә омтылган мөселманның уразасы түбәндәгечә булырга тиеш:

**Уразалы кеше үзенең күзләрен һәртөрле яманлыклардан сакларга тиеш.**

Күз зинасыннан саклану лязем. Башкаларның малына, намусына яман күз белән карарга ярамый. Кемнеңдер малына кызыгып карау – тыела. Боларның барысын да Аллаһы Тәгалә Бирүче.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Кем дә кем күзләрен харам белән тутырса, Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә ул кешенең күзләрен ут белән тутырыр», – дигән.

**Колакларын һәртөрле яман сүзләрне ишетүдән сакларга тиеш.**

Ураза тотучы колакларын яман сүзләргә шаһит булудан сакларга тиеш. Моның өчен аңа яман сүзләр сөйләшүче кешеләр янында утырмаска кирәк.

Әгәр ул берәр мәҗлестә динне мәсхәрәләү, сүгү һәм мыскыл итүгә шаһит булса, андагы кешеләрне бу хакта сүз катудан туктатырга яисә алар яныннан чыгып китәргә тиеш.

**Телен һәртөрле ялган вә яман сүзләр сөйләүдән, ялган антлар бирүдән, буш сүзләрдән сакларга тиеш.**

Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә ялганны тыя. Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән китерелә: «Аллаһыга һәм Кыямәт көненә [аның хаклыгына, котылгысызлыгына] ышанган кеше яхшы сүз сөйләсен яки эндәшмәсен!» (Әл-Бохари).

**Мөселман кешесе барлык әгъзаларын да яман гадәтләрдән сакларга тиеш.**

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Бер кеше башкаларның яман сүзләрен вә гамәлләрен кире какмаса, «ураза тотам», дип, ашамый-эчмичә һәм җенси теләкләрен тыеп торуыннан бернинди дә файда булмас. Бары фарызы гына үтәлгән булыр» (Әл-Бохари).

**Ифтар вакытында күп ашарга ярамый.**

Кояш батканчы буш торган ашказанын кисәк кенә шыплап тутырып кую сәламәтлеккә файда бирмәс. Моны тыйб (медицина) фәне дә раслый.

Асылда, ахшамга азан әйтелгәч, берничә хөрмә яки зәйтүн җимеше, яисә бер стакан су белән ифтар кылырга кирәк. Аннары ахшам намазы укыла. Намаздан соң ифтар ризыгы белән авыз ителә.

Ләкин бик күп ашап куюдан сакланырга кирәк.

**Ураза тотучы ифтар кылганда (авыз ачканда) курку белән өмет арасында булырга тиеш.**

Ләкин: «Аллаһы ничек тә гафу итәр әле» яки «Уразам кабул ителгәндер», – дип, нык ышаныч белдерергә дә кирәкми, чөнки, Аллаһы тели икән – гафу итә, теләми икән – гафу итми.

Шуңа күрә, ураза тотучы өмет белән курку арасында булырга тиеш. Уразаны Аллаһы ризалыгы өчен тотарга тырышу лязем. «Кабул булмаса, нишләрмен?» – дип, куркý тиешле. Шул ук вакытта, уразаң кабул булсын өчен Аллаһыга дога кылырга кирәк.

## РАМАЗАН – КОРЪӘН ИҢГӘН АЙ

Мөхтәрәм җәмәгать! Рамазан-шәриф – Аллаһының Китабы Коръәни Кәрим иңгән ай, ягъни Коръәнне уку, өйрәнү, аның аятьләре, сүрәләре турында уйлау, фикер йөртү һәм, әлбәттә, Коръән буенча яшәү ае.

Коръән укуның фазыйләтләре турында сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә болай дигән: «Коръән укыгыз, чөнки Аллаһының Китабыннан укылган һәрбер хәреф өчен ун савап биреләчәк, мин «Әлиф ләм мим» бер хәреф дип әйтмим, чөнки аларның һәрберсе – аерым хәреф, аларның барысы өчен дә унар савап биреләчәк» (Әт-Тирмизи).

Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе риваять кылганча, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Әгәр бер кеше мөселман кардәшен бер кайгысыннан арындырса, Кыямәт көнендә Аллаһы ул бәндәне бер кайгысыннан арындырыр. Әгәр бер кеше бер фәкыйрьнең хәлен җиңеләйтсә, Аллаһы аның хәлен бу дөньяда да һәм Ахирәттә дә җиңеләйтер. Бер кеше үзенең кардәшенә ярдәм иткәндә, Аллаһы аңа Үзенең ярдәмен дә ирештереп торыр. Гыйлем алу юлына баскан кешегә – Аллаһы җәннәт юлын җиңеләйтер. Кешеләр Аллаһы

йортына җыелып, Аның Китабын укыганда, мөселманнарның җаннарына тынычлык иңәр, алар бәрәкәтле булыр вә фәрештәләр алар өстендә канатларын җәеп торыр. Алар Аллаһы Тәгаләгә якын булыр» (Мөслим, Әбү Давыд, Әт-Тирмизи, Ибне Мәҗе).

### УРАЗА ҺӘМ КОРЪӘН КЫЯМӘТТӘ ЯКЛАУЧЫ БУЛЫР

Әгәр мөселман кешесе көндез ураза тотса, төннәрен Коръән укыса, Кыямәт көнендә аның ике яклаучысы булачак. Алар мөселманнарга Аллаһыдан ярлыкау һәм җәһәннәм утыннан котылу сораячак. Шул ике яклаучының берсе – ураза, икенчесе – Коръән булыр. Хәдистә: «Ураза һәм Коръән Хисап көнендә Аллаһының колын яклаячак. Ураза: «Йә, Раббым, көндез мин аны ризыксыз вә сусыз тилмерттем, шунлыктан мин аның өчен Синнән ярдәм сорыйм», – дип әйтер. Коръән: «Йә, Раббым, мин аны төнге йокысыннан калдырдым, шуңа күрә аңа Үзеңнең рәхмәтеңне ирештерсәң иде», – дияр. Аларның үтенечләре кабул ителәчәк», – дип әйтелгән (Әхмәд бине Хәнбәл).

Ибне Габбас радыяллаһу ганһе болай дип риваять кылган: «Җәбраил галәйһиссәлам Рамазан аеның һәр төнендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән очрашып, аның белән бергә Коръән өйрәнгән» (Әл-Бохари, Мөслим).

Кадерле дин кардәшләрем! Аллаһы Раббыбыз безгә дә Рамазан аеның төннәрендә уяу торып, Аллаһының Китабын укып, Аның хисапсыз әҗер-савапларына ирешергә насыйп итсә иде.

Расүли Әкрам салләллаһу галәйһи вә сәлләм икенче бер хәдисендә болай дигән: «Ике төрле кешедән генә көнләшергә ярый: аларның беренчесе – Аллаһы Тәгалә Коръән байлыгы биреп, шуның белән көн-төн мәшгуль булучыдан, икенчесе – Аллаһы Тәгалә күп нигъмәтләр биреп, шул байлыгын изге юлда сарыф итүчедән» (Әл-Бохари, Мөслим).

Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгалә һәрбарчаларыбызга да Коръәни Кәрим буенча яшәп, ике дөньяда да бәхет-сәгадәткә ирешүчеләрдән булуны, Үзенең ризалыгына ирешүне насыйп итсә иде. Әмин.

**Тимергали хәзрәт Юлдашев,**
«Саләх» мәчете имам-хатыйбы

# Ураза буенча гомум сораулар

**? Балигъылык яшенә җитмәгән бала нинди хөкемдә була?**

**ҖАВАП:** Балигъылык яшенә җитмәгән балага ураза тоту мәҗбүри түгел. Әмма һәр гыйбадәткә кече яшьтән иялəштерү күркәм гамәл. Бу очракта баланың физик мөмкинлекләрен истә тотарга кирәк. Яшь организмга зыян салынырга тиеш түгел.

**? Әгәр хәез хәле ахшам намазына берничә минут кала башланса, ураза бозыламы?**

**ҖАВАП:** Әйе, ураза бозыла, ул көнне каза итеп тотасы була.

**? Ураза вакытында дару эчсәң, ураза бозыламы?**

**ҖАВАП:** Әйе, ураза бозыла. Уразаны түбәндәге дүрт төрле эш боза:

1. Борчак кадәр генә булса да берәр ризык яки дару йоту.
2. Бер тамчы кадәр генә булса да су яки дару йоту.
3. Якынлык кылу.
4. Авыз тутырып косу.

**? Уразаның тәнебезгә файдасы бармы, яки ул бер гыйбадәт буларак кына барамы?**

**ҖАВАП:** Ураза – гыйбадәт, әлеге гыйбадәт Аллаһы Тәгалә өчен башкарыла. Әмма Аллаһы Тәгаләнең өстебезгә йөкләгән һәр гыйбадәтендә тәнебезгә дә, рухи хәләтебезгә дә файда бар.

Ураза ризык кабул итүдән генә тыелу түгел, безнең уй-фикерләребез дә уразада. Рамазан аенда кеше төрле начар фикерләрдән, гайбәт сөйләүдән тагын да күбрәк тыелып тора. Шулай ук тәнебез дә пакьләнә: ашказаныбыз ел дәвамында җыелган зыянлы, токсинлы матдәләрдән арына.

Ураза – ул Аллаһы Тәгалә биргән нигъмәтләр өчен шөкер итү. Шөкер итү акыл ягыннан да, шәригать буенча да фарыз.

Ураза фәкыйрьләргә мәрхәмәтле булырга өйрәтә. Байларга ел буе ач торган фәкыйрьләрнең хәленә төшенергә ярдәм итә.

Ураза шәһвәтне (җенси теләкләрне) тыя, чөнки күзгә матур булып күренгән нәрсәләр җенси теләкләрне уята. Ач торганда исә тыелып калып була.

**? Онытылып берәр нәрсә ашау уразаны бозамы?**

**ҖАВАП:** Юк, бу очракта уразагыз бозылмый, дәвам итеп тотып бетерергә кирәк. Әмма уразалы булуыгыз исегезгә төшү белән, ашаудан туктарга кирәк.

**? Организмда су балансын саклар өчен, ифтарны (авыз ачуны) ничек башкарырга кирәк?**

**ҖАВАП:** Авыз ачуны су белән башлый аласыз. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Су пакьләндерә», – дип әйткән. Башта җиңел ризык, намаз укыгач кына авыррак ризык кабул итегез.

**? Тәравих намазыннан арып кайтып, иртән сәхәргә йоклап калганбыз. Сәхәр ашамыйча гына уразага керергә ярыймы?**

**ҖАВАП:** Бик арыган көннәрдә кеше сәхәр вакытында уяна алмыйча, иртәнге намаз кергәч кенә торырга мөмкин. Бу вакытта сәхәр ашарга ярамый. Әмма ул кеше барыбер ниятләп, уразага керә. Сәхәрсез ураза авыррак тотылачак, чөнки Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Сәхәр ашагыз, дөреслектә, сәхәрдә бәрәкәт бар», – дип әйткән. Әмма Аллаһы Тәгаләдән җиңеллек сорап, бу көнне ураза тотарга тырышырга кирәк, чөнки пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кем Рамазан аеның бер көн уразасын калдырса, ул аны ел буе тотып та тутыра алмаячак», – дип әйтә. Әмма бу хәдис, казага калган уразаны тотмаска кирәк, дигәнне аңлатмый. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм шушы хәдисе белән Рамазан ае уразасының бик фазыйләтле икәнлегенә игътибар иткән.

**? Мин намаз укымыйм, әмма ураза тотам. Андый ураза кабул кылынамы?**

**ҖАВАП:** Ислам дине 5 баганага нигезләнгән. Намаз һәм ураза – алар икесе ике гыйбадәт. Шуңа күрә, сез намаз укымасагыз да, уразагыз, иншәАллаһ, кабул булачак.

**«Рамазан. Ураза: еш бирелә торган сораулар»** китабыннан


Фото: yandex.ru

# РАМАЗАН УНКӨНЛЕКЛӘРЕНЕҢ ХИКМӘТЕ

**Газиз дин кардәшләрем! Күп әҗер-саваплар, дәрәҗәләр вәгъдә ителгән Рамазан аеннан файдаланып калыйк. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә болай дип әйткән: «Бер адәм Рамазан аен шатланып каршы алса һәм Рамазан аеның үтеп китүенә күңеле белән яхшы айлар үтте дип кайгырса, ул адәмгә мәңгелек сәгадәт, рәхәт йорты булган җәннәт вәҗиб (тиешле) булыр».**

Икенче бер хәдистә Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Әгәр кешеләр Рамазан аеның бөтен хасиятләрен, савапларын белсәләр, бөтен ел әйләнәсе Рамазан ае булуын теләрләр иде». Бу хәдистән аңлашылганча, Рамазан аеның хасиятләре күп булып, хәтта без аның күп өлешен дөньяда, алдагы гомеребездә һәм Ахирәттә күрәчәкбез, сөенәчәкбез.

Мөхтәрәм җәмәгать! Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Рамазан аеның беренче ункөнлеге Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте көннәре, икенче ункөнлеге гөнаһлардан пакьләнү көннәре һәм соңгы ункөнлеге җәһәннәм утыннан котылу көннәре», – дигән. Ягъни, Рамазан ае тулаем алганда саваплы һәм изге ай булып, Пәйгамбәребез безгә һәрбер вакытының хасиятләрен җиткерә. Һәрбер эшнең үз нәтиҗәсе булган кебек, ошбу айның да һәр вакыты безгә билгеле бер җимеш китерә.

Рамазан-шәриф аеның беренче ун көне – Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешергә мөмкинлек бирелә торган вакыт ул. Аллаһы рәхмәтенә ирешү исә бик тә мөһим нәрсә, аңа ирешүче кеше чын бәхет иясе булды дигән сүз. Дөнья һәм Ахирәт бәхете бары тик Аллаһы Тәгалә рәхмәтенә генә ирешеп килә. Дөрестән дә, безнең нindидер уңышка ирешүебез, эш-максатларыбызның тормышка ашуы фәкать Аллаһы рәхмәте һәм ярдәме белән бәйле. Бервакыт Аллаһының Расүле сәхабәләрен җыйды да: «Бер кеше дә гамәлләре белән генә җәннәтле булмый, бары тик Аллаһының рәхмәтенә ирешеп кенә җәннәтле була», – диде. Чыннан да, гамәлләребезне кылып, алар Аллаһының рәхмәтенә ирешүгә сәбәп булса, без мәңгелек бәхеттә булабыз икән.

Ә инде Рамазан аеның икенче ун көне – гөнаһларның гафу ителү көннәре (мәгъфирәт). Әлбәттә, Аллаһы Тәгалә гөнаһларыбызны ярлыкасын өчен, Аңа ихлас күңелдән мөрәҗәгать итеп, гафу итүне сорарга кирәк. Бер риваять буенча шундый тирән мәгънәле, уйландыра торган мәгълүмат хәбәр ителә: көннәрдән бер көнне пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына бер кеше килә дә фәкыйрьлектән, акча җитмәүдән зарлана. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа: «Аллаһыдан гөнаһларың өчен гафу итүен сора», – дип киңәш бирә. Икенче кеше килеп: «Хатыным белән ничә ел торабыз, әмма балаларыбыз юк», – дип, борчуы белән уртаклаша. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа да: «Тәүбә-истигъфар кылыгыз, гөнаһлар өчен Аллаһыдан гафу үтенегез», – дип җавап бирә. Өченче кеше килеп Пәйгамбәребезгә: «Безнең җирлектә корылык, инде күп вакыт яңгыр яумый», – дип әйтә, дүртенче кеше исә: «Бездә яңгыр ява, ләкин уңыш юк», – дип зарлана. Аларга да Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм шул ук сүзләрне кабатлый: «Тәүбә-истигъфар кылыгыз, Аллаһыдан гөнаһларыгыз өчен гафу үтенегез», – дип нәсыйхәт кыла. Моны ишеткән сәхабәләр аптырап: «Йә, Аллаһының Расүле, дүрт кеше дүрт төрле мәсьәлә белән мөрәҗәгать итте, әмма барысына да бер үк киңәш бирдең...» – дип әйтә. Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләренә: «Бу минем сүзем түгел, моны Аллаһы Тәгалә Коръәндә шулай киңәш итә...» – дип җавап бирә. Әйе, Аллаһы Тәгаләнең мәгъфирәте (ярлыкавы) олуг нигъмәт, Галәмнәрнең Раббысы кичермәсә, безне якын итмәсә, без мескен, ятим хәлдә калабыз.

Рамазан аеның өченче ун көне – тәмуг утыннан котылу көннәре. Бу вакыт – уразаның ахыры. Пәйгамбәребез бер хәдисендә: «Гамәлләр ахырына карап бәяләнә», – дип әйткән. Ягъни, эшне башлау гына түгел, тулы рәвештә тәмамлау да бик мөһим икән. Кем дә кем шул көннәрне тәкъвалык белән ихластан гыйбадәттә үткәрсә, аның җәһәннәм утына керүгә сәбәпче булган гөнаһлары ярлыканыр һәм Рамазан ае ахырына ул гөнаһсыз, чиста күңелле бала кебек булыр. Шунысын да аерым әйтеп китәргә кирәк: ахыргы ункөнлегенә мең айдан да хәерлерәк булган Кадер кичәсе дә туры килә. Игътикяф гыйбадәтенең дә нәкъ менә шушы чорга билгеләнүендә зур хикмәт бардыр.

Шулай итеп, олуг Рамазан аенда Аллаһы Тәгалә мөэмин-мөселманнарга бик күп бүләкләр вәгъдә итә, белгәнебезчә, Аллаһы Раббыбыз вәгъдәсен бозмас. Ә безгә бары тик Аллаһының шушы рәхмәтеннән файдаланырга гына кирәк. Аллаһы Тәгалә хәерле сәламәтлекләр биреп, Рамазан айларыбызны да изгелектә, гамәл-гыйбадәттә үткәрүләребезне насыйп итсә иде.

**Инсаф хәзрәт Ибатуллин,**
«Динислам» мәчете имам-хатыйбы

# Кемгә васыять калдырыла?

**СОРАУ:**
**Әссәләмү галәйкүм! Дус кызымның өлкән яшьтәге әнисе миңа үзенең фатирын васыять итеп калдырырга тели. Әмма аның балалары һәм туганнары бар. Бу очракта ул шундый васыятьнамә калдыра аламы?**

**ҖАВАП:**

بِسْمِ ٱللَّهِ ٱلرَّحْمَٰنِ ٱلرَّحِيمِ

Мәрхәмәтле һәм Рәхимле Аллаһы исеме белән. Вә галәйкүм әссәләм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ.

Сез дус кызыгызның әнисенең варислары исемлегенә кермисез, шуңа күрә ул сезгә васыятьнамә калдыра ала. Әмма шул ук вакытта мирас калдыручының малыннан иң беренче чиратта җирләүгә, аның бурычларын түләүгә чыгымнар бүленеп бирелергә, аннан соң гына васыятьнамәнең гамәлгә керүен онытмаска кирәк. Моннан тыш, васыятьнамәдә каралган мирас күләме алдагы ике эшне башкарганнан соң калган барлык мирасның өчтән береннән артмаска тиеш.

**ДӘЛИЛ:**

«Хакыйкатьтә, Аллаһы һәркемгә үзенә тиеш булганын бүлеп бирде инде, һәм вариска васыятьнамә юк».

Кара: «Сөнән Әбү Давыд», Әбү Давыд Әс-Сиҗистани, №2870.

Сәгъд радыяллаһу ганһе болай дигән: «Мин Мәккәдә авырып ятканда, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәлемне белергә килде, һәм мин аңа: «Минем милкем бар, аны тулысынча васыять итә аламмы?» – дидем. Ул моңа: «Юк», – дип җавап бирде. Шунда мин яртысын мирас итеп калдырып булу-булмавы турында сорадым. Ул аңа да: «Юк», – дип җавап бирде. Шунда мин тагын бер тапкыр өчтән берен мирас итеп калдырып булу-булмавы турында сорадым. Ул өчтән берен мирас итеп калдырып булуын әйтте [хуплады дип әйтергә кирәк]...»

Кара: «Сахих Әл-Бохари», №5039.

«Васыятьнамә милекнең өчтән бер өлешен мирас итеп калдырганда дөрес булыр, бу хәтта варислар рөхсәтеннән башка да мөмкиндер».

Кара: «Әл-Һидәя», Борханеддин Әл-Мәргинани, 513/4.

«Әгәр җирләү өчен чыгымнардан, һәм бурычларын түләгәннән соң, [вафат булган кешенең милкеннән] милек калса».

Кара: «Әл-Һидәя», Борханеддин Әл-Мәргинани, 513/4.

Аллаһы яхшырак Белүчедер.

# Тәһарәт алганда су йотсаң, ураза бозыламы?

**СОРАУ:**
**Әссәләмү галәйкүм! Тәһарәт алганда тамакка бер тамчы су китте. Уразам бозылганмы икән инде? Ялгышып йотылган су уразаны бозмый дип ишеткәнем бар.**



Фото: shutterstock.com

**ҖАВАП:** Вә галәйкүм әссәләм! Уразаны боза торган гамәлләрне, ниятенә һәм нәтиҗәләренә карап, өч категориягә бүләләр:

1. Уразаны белә торып бозу. Ураза кергәч, аны белә торып бозган кеше ике ай тоташтан ураза тотып, кәффарәт түләргә тиеш.
2. Уразаны ялгышып бозу. Уразалы икәнен белә торып, ялгыш уразаны боза торган гамәл кылу, мәсәлән, тәһарәт алганда бер тамчы су йоту. Кешенең ураза бозу нияте булмаса да, мондый очракларда бозылган уразаны бер көн ураза тотып каза кылу тиешле була, кәффарәт кылу кирәкми.
3. Онытып уразаны бозу. Ураза икәнен онытып, кеше уразаны боза торган гамәл кылса (ашаса, эчсә, җенси мөнәсәбәткә керсә), ураза бозылмый, әмма ураза икәне исенә төшүгә үк кеше гамәлен туктатырга тиеш.

Бер карашка, «ялгышып» һәм «онытып» дигән гыйбарәләр мәгънәдәш булсалар да, шәригать аларны аера. Шунлыктан, мөселман кешесе уразасына, гамәлләренә бик игътибарлы булырга тиеш.

Сезнең очракта уразагыз бозылган, аны бер көн ураза белән каза кылу тиешле булыр.

Ә Аллаһы яхшырак белүче!

**ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең фәтвалар бүлеге (даруль-ифта)**

ДИН вә МӘГЫЙШӘТ
№ 03 (332) март, 2023 | шәгъбан - Рамазан, 1444

# Татарстанда «Рамазан – изге гамәлләр ае» хәйрия марафоны башланды



Фото: dumrt.ru

**Рамазан аеның беренче көнендә, Татарстанда күпьеллык гадәт буенча «Рамазан – изге гамәлләр ае» дип исемләнгән хәйрия марафоны башланып китте. Ел саен игълан ителә торган бу акция ТР мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан авыру балаларга, аз керемле гаиләләргә һәм мохтаҗларга ярдәм йөзеннән оештырыла. Рамазан аенда мөселманнар хәйриячелектә актив катнаша, чөнки Рамазанның төп асылы – үз малыңнан мохтаҗларга өлеш чыгаруда. Бу изге айда мохтаҗларга һәм авыруларга карата игелек кылган һәм юмартлык күрсәткән өчен, әҗер-савап күп тапкырлар арттырып бирелә һәм инсанны Аллаһы Тәгаләгә якынайта. Быел да Татарстан мөфтиятенең «Зәкят» хәйрия фонды марафон кысаларында авыру балаларга ярдәм күрсәтәчәк, мохтаҗлар өчен ифтарлар уздырачак, аз керемле гаиләләрне ризык белән тәэмин итәчәк, социаль ифтарлар оештырачак, мохтаҗлар файдасына фитр садакасы, фидия һәм зәкят җыеп таратачак. Быел акция барышында түбәндәге башлангычлар тормышка ашырылачак.**

### 1. АВЫРУ БАЛАЛАРГА ЯРДӘМ ИТҮ

Узган елда «Рамазан – изге гамәлләр ае» акциясе кысаларында 20 балага ярдәм күрсәтелде. 2023 елда Рамазан аенда «Зәкят» хәйрия фонды мохтаҗ гаиләләрдән шулай ук 20 авыру балага булышырга ниятли.

Балаларга ярдәм итүнең 4 юлы бар:

**1.** 7715 номерына ЗАКЯТ сүзен язып смс-хәбәр җибәрергә.

**2.** Картага күчерергә:

а) 5469 9801 5775 7903 номерлы Саклык банкы картасы (Илнур Мәхмүт улы Ә.).

б) 5336 6903 6390 5623 номерлы Саклык банкы картасы (Илнур Мәхмүт улы Ә.).

в) 4279 3806 8793 7898 номерлы Саклык банкы картасы (Илнар Равил улы Р.).

**3.** Турыдан-туры **zakyatrt.com** сайты аша.

**4.** Исәп-хисап счетына.

*(Тулырак мәгълүмат dumrt.ru сайтында).*

### 2. МОХТАҖЛАР ФАЙДАСЫНА ЗӘКЯТ, ФИТР САДАКАСЫН ҺӘМ ФИДИЯ ҖЫЮ

Хәнәфи мәзһәбе буенча, фитр садакасын (бары тик мохтаҗ мөселманнарга гына бирелә), ризык/азык-төлек белән генә түгел, акчалата да бирергә мөмкин. Мохтаҗлар бу акчаны үзләре теләгәнчә (бурыч, дәвалану һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү, дарулар, кием-салым, азык-төлек сатып алу һ.б. өчен) тота ала. Моңа бәйле рәвештә, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды, Коръән нигезендә халыкның мохтаҗ катламнарына бүлеп бирү максатыннан, фитр садакасы, фидия һәм зәкят җыя башлый. Узган елда «Зәкят» хәйрия фонды 1 400 000 сум күләмендә фитр садакасы һәм фидия җыйды һәм мохтаҗларга таратты.

### ФИДИЯ, ФИТР, САДАКА ҺӘМ ЗӘКЯТНЕ УҢАЙЛЫ ИТЕП НИЧЕК ТҮЛӘРГӘ?

✔ Фитр: 2202 2004 8668 4499 номерлы Саклык банкы картасына (Динар Дамирович З.); Фитр садакасын 23 марттан 20 апрельгә кадәр күчерергә мөмкин.

✔ Фидия: 5336 6902 2342 7776 номерлы Саклык банкы картасына (Гүзәлия Галимҗановна В.)

✔ Зәкят: 2202 2056 7305 9207 номерлы Саклык банкы картасына (Әмир Рафисович Ф.) яки 7715 номерына ЗАКЯТ сүзен язып смс юлларга;

✔ Садака: 5336 6902 4116 2264 номерлы Саклык банкы картасына (Булат Раифович М.) яки 7715 номерына САДАКА сүзен язып смс юлларга; Мәсәлән, САДАКА 100.

✔ Турыдан-туры сайт аша: **zakyatrt.com.**

✔ Яки ТР Дәүләт хезмәтләре порталы аша. Моның өчен шәхси кабинетка кереп, эзләгечтә Благотворительный фонд «Закят»не табып, төймәгә басарга һәм зәкят, садака һәм фитрны комиссиясез түләргә мөмкин. (Һәр очракта 15000 сум күләмендәге акчаны комиссиясез күчерергә мөмкин).

✔ Яки исәп-хисап счетлары аша.

*(Тулырак мәгълүмат dumrt.ru сайтында).*

### 3. АЗ КЕРЕМЛЕ ГАИЛӘЛӘРГӘ ҺӘМ МОХТАҖЛАРГА АЗЫК-ТӨЛЕКЛӘТӘ ЯРДӘМ КҮРСӘТҮ

Узган елда ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды, битараф булмаган кешеләр булышлыгы белән, 550 аз керемле

гаиләгә 3,5 тонна азык-төлек тапшырылды. Быел да, ким дигәндә, 500 мохтаҗга он, карабодай ярмасы, көнбагыш мае, тушенка, шикәр, токмач, чәй һәм хөрмә җимешеннән торган ризык җыелмаларын өләшү көтелә.

**ЯРДӘМНЕ ӨЧ ЮЛ БЕЛӘН КҮРСӘТЕРГӘ МӨМКИН:**

**1.** Турыдан-туры zakyatrt.com сайты аша.

**2.** 2202 2021 3911 9295 номерлы Саклык банкы картасына күчерергә (Зилә Ириковна И.)

**3.** Исәп-хисап счетына.

*(Тулырак мәгълүмат dumrt.ru сайтында).*

## 4. 11 НЧЕ РЕСПУБЛИКАКҮЛӘМ ИФТАР

11 нче Республикакүләм ифтар үткәрелү көне һәм урыны турында өстәмә рәвештә хәбәр ителәчәк. 11 нче Республикакүләм ифтары волонтеры булыр өчен, **muslimmol** телеграм каналында яки **+7 (843) 237-86-18** телефоны буенча шалтыратып теркәлергә кирәк.

## 5. МОХТАҖЛАР ӨЧЕН ХӘЙРИЯ ИФТАРЛАРЫ

ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды Татарстан Республикасы районнарында ифтарлар уздыра. Узган елда Казан шәһәрендә һәм республика районнарында 3 725 мохтаҗ өчен 34 хәйрия ифтары оештырылды. Быел да аларны көн саен үткәрү көтелә. Сез дә бу ифтарларга килә яки аз керемле дин кардәшләргә авыз ачтыру мәҗлесен оештыруга өлеш кертә аласыз.




Фото: dumrt.ru

**ИФТАР УЗДЫРУ ӨЧЕН АКЧАНЫ ДҮРТ ЮЛ БЕЛӘН КҮЧЕРЕП БУЛА:**

**1.** 7715 номерына ИФТАР сүзе белән смс хәбәр юлларга

**2.** 5469 6200 1751 2813 номерлы Саклык банкы картасына (Булат Рафикович М.)

**3.** Турыдан-туры **zakyatrt.com** сайты аша.

**4.** Исәп-хисап счетына.

*(Тулырак мәгълүмат dumrt.ru сайтында).*

## 6. КАЗАН ҺӘМ ТАТАРСТАН МӘЧЕТЛӘРЕНДӘ ИФТАРЛАР

Казанда ифтарлар 42 мәчеттә узачак. Аларның исемлеге белән ТР Диния нәзарәте сайтында танышып була. Ифтарларны үз исемеңнән оештыру өчен, күрсәтелгән мәчетләрнең имамнарына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Ай дәвамында әлеге исемлек тулыланырга мөмкин.

## 7. ТАТАРСТАННЫҢ БАРЛЫК КОЛОНИЯЛӘРЕНДӘ КӨН САЕН ИФТАРЛАР УЗДЫРЫЛАЧАК

Ураза тоту һәм гыйбадәт кылу өчен шартлар тудырылачак, Гает намазлары үткәреләчәк.

**dumrt.ru** сайтыннан

# ТР МДНнең «ХОЗУР» НӘШРИЯТ ЙОРТЫ СӘЙДӘ АБЫСТАЙ АППАКОВАНЫҢ «ТУЗМАС БҮЛӘК» КИТАБЫН НӘШЕР ИТТЕ

**Динебездә башкаларны тәүфикъ-һидаятькә чакыруга әһәмиятле урын бирелә. Вәгазь, нәсыйхәтләр кешенең күңелен нурландыра, әдәп-әхлакка өйрәтә, бу җир йөзенә болай гына җибәрелмәвебезне, ә билгеле бер максатларыбызның барлыгын аңлап яшәргә ярдәм итә.**

Халкыбызны вәгазьләү эшендә җиң сызганып хезмәт итүче танылган абыстай, мөгаллимә Сәйдә апа Аппакова күп еллар дәвамында динебез Исламга нигезләнгән әдәп-әхлак тәрбиясен тормышта файдалану хакында бәян итә. Үзе дә тугызынчы дистәсен ваклаучы абыстай табигый талантын эшкә җигеп, кечкенәдән белеп-өйрәнеп үскәннәрен халыкка җиткерү юлында хезмәт итә.

«Тузмас бүләк» китабы Сәйдә абыстайның дин белән бергә үрелеп яшәлгән, тәрбиягә, әдәп-әхлакка нигезләнгән тормышына кабат күз салу ул. Җыентыкта абыстайның кечкенә чактагы, яшьлек елларындагы булган кызыклы һәм шул ук вакытта гыйбрәтле вакыйгалары, төрле темаларга сөйләнгән вәгазьләре, әйткән үгет-нәсыйхәтләре урын алган. Сәйдә апа Аппакова бик оста итеп гаилә, ир-ат һәм хатын-кыз, килен-кайнана мөнәсәбәтләренең нечкәлекләрен тасвирлап бирә, гаиләдә тынычлык, татулык һәм үзара хөрмәт хисләре хакимлек итсен өчен, ниләр эшләргә кирәк булу серләре белән уртаклаша. Китапта туган илгә, туган телгә, гореф-гадәтләребезгә карата сакчыл булу, бу кыйммәтле төшенчәләребезне күз карасыдай саклау мөһимлегенә зур урын бирелгән.

Әлеге китап киң катлау укучылары өчен тәкъдим ителә. Китап һәркем өчен дә файдалы булыр дигән өметтә калабыз.

Китапны «Хозур» нәшрият йорты кибетләрендә сатып алырга һәм җир йөзенең теләсә кайсы почмагыннан заказ бирергә мөмкин.




**Кибет: Казан шәһ., Париж коммунасы ур., 6нчы йорт. Тел.: +7 960 072-74-63;**

**Склад: Казан шәһ., Газовая ур., 14нче йорт. Тел.: +7 (966) 250-00-09;**

**Интернет-кибет: huzurshop.ru**

РЕКЛАМА 12+



Фото: shutterstock.com

### БАЛАНЫҢ АТА-АНАСЫ АЛДЫНДАГЫ ВАЗИФАЛАРЫ

- ✔ Әти-әни берәр нәрсә әйткәндә, аларны игътибар биреп тыңларга кирәк
- ✔ Әти-әни торып баскач, алар белән бергә торып басарга кирәк
- ✔ Алар кушканнарны үтәргә
- ✔ Алар чакырганда шунда ук барырга
- ✔ Аларга карата һәрвакыт яхшы мөнәсәбәттә булырга
- ✔ Әти-әнине үз теләкләреңне үтәргә мәҗбүр итәргә ярамый
- ✔ Балалары аларны тыңлаганы һәм алар кушканны үтәгәннәре өчен әти-әнине шелтәләргә ярамый
- ✔ Әти-әнигә үпкә һәм ачу белән карарга ярамый
- ✔ Әти-әнигә каршы дәшәргә һәм алар кушканнарны эшләүдән баш тартырга ярамый

### АТА-АНАНЫҢ БАЛАСЫ АЛДЫНДАГЫ ВАЗИФАЛАРЫ

- ✔ Балаларның үз-үзләренә карата яхшы мөнәсәбәт булдыру өчен шартлар тудырырга
- ✔ Балаларның яхшы мөнәсәбәт белдерүенә кагылышлы сорауларда аларның көченнән килми торган әйберләрне таләп итмәскә
- ✔ Авыр мизгелләрдә үз таләпләрең үтәлүгә басым ясамаска
- ✔ Аллаһы Тәгаләнең әмерләрен үтәүдә киртә куймаска
- ✔ Аларны үстерүегез һәм тәрбияләвегез белән аларны битәрләмәскә

### ДУС-ИПТӘШЛӘРГӘ КАРАТА ТИЕШ БУЛГАН МӨНӘСӘБӘТ

- ✔ Аларны елмаеп каршы алырга
- ✔ Аларга беренче булып сәлам бирергә
- ✔ Аларга яхшы мөнәсәбәттә булуыңны белдерергә
- ✔ Аларга урын бирергә
- ✔ Дус-иптәшләрең чыгып киткәндә, аларны озатырга чыгарга
- ✔ Үзара сөйләшкәндә, аларны бүлдермичә тыңларга
- ✔ Алар белән телләшмәскә һәм бәхәскә кермәскә
- ✔ Кызыклы вакыйгалар сөйләргә
- ✔ Аларга күркәм исемнәр белән мөрәҗәгать итәргә

### КҮРШЕЛӘРГӘ КАРАТА ТИЕШ БУЛГАН МӨНӘСӘБӘТ

- ✔ Очрашканда беренче булып сәлам бирергә
- ✔ Сөйләшеп торуларны озакка сузмаска
- ✔ Кирәкмәгән сораулар бирмәскә
- ✔ Авырган вакытта аларны зиярәт итәргә
- ✔ Берәрсенең якын кешесе вафат булса, аның кайгысын уртаклашырга
- ✔ Шатлыклы мизгелләрендә шатлыгын уртаклашырга
- ✔ Күршеңнең балаларын очраткач, алар белән ягымлы сөйләшергә
- ✔ Зур булмаган хата-кимчелекләрне кичерергә
- ✔ Әгәр алар хата җибәрсә, йомшак һәм хикмәт белән аңлатырга
- ✔ Күрше хатыннарга күтәрелеп карамаска
- ✔ Күршеләргә ярдәм кирәк булганда, ярдәм итәргә

### ЭШЧЕЛӘРГӘ КАРАТА ТИЕШ БУЛГАН ВАЗИФАЛАР

- ✔ Аларга авыр һәм көчләреннән килми торган эш йөкләмәскә
- ✔ Аларның мәшәкать һәм авырлыклары туса, ярдәм итәргә
- ✔ Зур булмаган хата-кимчелекләрен күрмәскә тырышырга
- ✔ Алар гафу үтенгәндә аларны кичерергә

### ЭШЧЕЛӘРНЕҢ ЭШ БИРҮЧЕ (ҖИТӘКЧЕ) АЛДЫНДАГЫ ВАЗИФАЛАРЫ

- ✔ Җитәкченең әмерләрен үтәргә
- ✔ Җитәкче янында булмаганда, аңа хәерлесен теләргә
- ✔ Вазифаларыңны намус белән башкарырга
- ✔ Җитәкче хатыннарының намус һәм абруен сакларга
- ✔ Җитәкченең балаларына карата яхшы мөгамәләдә булырга
- ✔ Җитәкченең малларына зыян китермәскә

### ИЛ БАШЛЫГЫНЫҢ ВАЗИФАЛАРЫ

- ✔ Үзеңнең кул астындагыларга карата яхшы мөгамәләдә булырга
- ✔ Ачуланмаска һәм оялтмаска, аларга карата көч кулланмаска
- ✔ Әмер бирер алдыннан һәрнәрсәне яхшылап уйлап бетерергә
- ✔ Кул астындагыларга түбәнсетеп карамаска һәм аларны дошман күрмәскә
- ✔ Үз-үзеңне кешеләр сине яратырлык һәм хөрмәт итәрлек итеп тотарга
- ✔ Кешеләрнең ихтыяҗлары хакында хәбәрдар булырга
- ✔ Галимнәрне хөрмәт итәргә
- ✔ Галимнәрнең якыннары һәм дусларына ярдәм күрсәтергә
- ✔ Кул астындагыларыңны һәрвакыт кайгыртып торырга һәм якларга

### ИЛ БАШЛЫГЫНА КАРАТА ВАЗИФАЛАР

- ✔ Аның ишек катында тормаска
- ✔ Кискен ихтыяҗ булмый торып, ярдәм сорамаска
- ✔ Ил башлыгының холкы йомшак булса да, аннан ерак торырга тырышырга
- ✔ Ил башлыгы йомшак булса да, аңа карата дорфа булмаска
- ✔ Ил башлыгы бөтен сорауларга җавап бирә алса да, артык күп сораулар бирмәскә
- ✔ Ил башлыгын очраткач, аның өчен дога кылырга
- ✔ Ил башлыгы хакында гайбәт таратмаска. Аның хакында начар сүзләр сөйләп йөрмәскә

### КАЗЫЙ КЕШЕНЕҢ ӘДӘПЛӘРЕ

- ✔ Аз сүзле булырга, дәшми торырга
- ✔ Җитди булырга
- ✔ Кулларны артык селкемәскә
- ✔ Кешеләргә начар булырга юл куймаска һәм кануннарны бозарга рөхсәт итмәскә
- ✔ Тол хатыннарга һәм ятим балаларга карата яхшы мөгамәләдә булырга
- ✔ Куелган сорауга җавап бирергә ашыкмаска
- ✔ Дәгъва белдерүчегә дә, җавапка тартылучыга да яхшы мөнәсәбәттә булырга
- ✔ Ике якның берсенә өстенлек бирмәскә, ягъни гадел хөкем итәргә
- ✔ Башка фикердә булучыга, ягъни оппонентыңа нәсыйхәт кылырга
- ✔ Дөрес хөкем чыгару өчен Аллаһы Тәгаләдән ярдәм сорарга

**Имам Әбү Хәмид Әл-Газалинең**
«Әдәпләр» китабыннан

# Ислам фәннәре маягы: «Мир гарәп» мәдрәсәсе тарихы


Фото: elements.envato.com

**«Мир гарәп» мәдрәсәсе Үзбәкстанның Бохара шәһәрендә урнашкан танылган уку йорты. Ул Урта Азиядә үзенең үзенчәлекле архитектурасы һәм бай тарихына ия булган иң борынгы мәдрәсәләрнең берсе.**

Мәдрәсә XVI гасырда – Урта Азиядә XV–XVI гасырларда хакимлек иткән үзбәк династиясе Шәйбәнидләр вакытында төзелгән. Мәдрәсә үзенең нигез салынучысы Сәед Габдулла Әл-Йәмәни хөрмәтенә аталган була, халык телендә ул «Мир гарәп» дип таныла.

Габдулла Әл-Йәмәни үз чорының танылган дин галиме була. Башта ул Йәмәннән Сәмәркандка күченә, соңрак Бохарада төпләнә. Биредә ул Бохара хакиме Гобәйдулла ханның рухи остазы була һәм монда киләчәктә үз исеме белән атап йөртеләчәк мәдрәсәгә нигез сала.

Күп кенә тикшерүчеләрнең фикеренчә, мәдрәсәнең төзелеш эшләре 1530 елда башланып, 1536 елда тәмамланган. Урта Азия стилендә эшләнгән мәдрәсәнең бинасы ике катлы аркадалар һәм зур ишегалдыннан гыйбарәт. Мәдрәсәгә ике якта урнашкан ачык зәңгәр төстәге гөмбәзләре булган керү урыныннан үтәләр, ул барысын да матур бизәлешле булуы белән җәлеп итә.

Мәчетнең эчке ягы да үзенчәлекле булуы белән таң калдыра. Мәдрәсә югары катларда яшәп укучы 114 шәкерткә исәпләнгән була. (Бу сан Коръәни Кәримдәге сүрәләр саны белән бәйле). Мәдрәсәнең укыту программасы Ислам дине хокукына, теологиягә һәм фәлсәфәгә игътибарны юнәлткән була. Уку вакытында шәкертләр фәнни тикшеренүләр һәм гыйлем алуның теле булган гарәп телен камил рәвештә белергә тиеш була.

Гасырлар дәвамында мәдрәсә Урта Азиянең мәдәни һәм рухи тормышында әһәмиятле роль уйнаган, Ислам диненең таралу үзәге булып торган, аның чыгарылыш укучылары танылган галимнәр һәм дин эшлеклеләре булып киткән.

Бүген «Мир гарәп» Бохараның истәлекле булган мәдәни ядкәре булып, бөтен дөньядан килүче кешеләрне үзенә җәлеп итеп тора. Бу Урта Азиянең бай мәдәни мирасы булуын һәм Ислам фәннәренең регион тарихында мөһим роль уйнавын ассызыклый.

### «МИР ГАРӘП» МӘДРӘСӘСЕ ГЫЙЛЕМНӘР ТУПЛАНГАН УРЫН

Татар халкының «Мир гарәп» мәдрәсәсендә гыйлем алу тарихы зур. Мәдрәсә XVIII–XIX гасырда татар шәкертләре арасында бик танылган була. Ул чакта татарлар мәдәни һәм рухи яңарыш кичерә һәм бу аларның Бохарада югары дини гыйлем эзләүләренә этәргеч була. Мөселман дөньясында мәдрәсә гыйлем бирүнең сыйфатлы булуы, галимнәренең бай тәҗрибәсе белән аерылып торган, нәкъ менә шул татар шәкертләрен җәлеп иткән дә.

Мәдрәсәдә гыйлем алучы татар шәкертләренең күбесе танылган дин белгечләре булып җитешә. Биредә гыйлем алган татар шәкертләренең берсе – Шиһабетдин Мәрҗани. Урта Азиядә гыйлем алуны тәмамлаганнан соң, ул Россиягә кайта һәм Ислам дине галиме булып хезмәт итә.

«Мир гарәп» мәдрәсәсендә татар шәкертләренең гыйлем алуы Бохараның бу вакытта Ислам гыйлеме һәм фәннәре үзәге булуында әһәмиятле роль уйный. Бу факт Ислам фәннәрен өйрәнү билгеле бер этник төркемнәр яки регион белән генә чикләнеп калмавын, ә гаять зур масштабларга таралган күренеш булуын, барлык мөселман дөньясыннан шәкертләр һәм галимнәрнең җәлеп ителүен ассызыклый.


Революциягә кадәрге чорда, Мәрҗанидән тыш, «Мир гарәп» мәдрәсен Ырынбур мөселман Диния нәзарәтенең беренче мөфтие Мөхәммәдҗан Хөсәенов, Россия мөселманнарының беренче мөфтие Галимҗан Баруди һәм башка танылган дин эшлеклеләре тәмамлаган.

Советлар чорында 1920 еллар башында мәдрәсә ябыла. Бөек Ватан сугышы вакытында дәүләт дин өлкәсендә кайбер юл куюларга бара һәм, шул рәвешле, Урта Азия мөселманнары Диния нәзарәте мөфтие Эшон Бабахан «Мир гарәп»нең эшчәнлегенең торгызылуына ирешә. Әзерлек эшләре башкарылганнан соң, 1946 елда мәдрәсә яңадан шәкертләр өчен ишекләрен ача.

1946–1956 һәм 1961–1989 елларда «Мир гарәп» СССРдагы бердәнбер мөселман уку йорты була. Анда гыйлем алу – 9, ә урта дөньяви гыйлемнәре булучылар өчен 4 елны тәшкил итә.

Совет чорында танылган укучылар арасында Россиянең югары мөфтие Тәлгать хәзрәт Таҗетдин, Россиянең мөфтиләр советы рәисе Равил хәзрәт Гайнетдин, Чечня республикасының беренче Президенты Әхмәд хәзрәт Кадыйров, Россиянең Азия өлеше мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Нәфигулла Аширов, ТРы Диния нәзарәтенең элеккеге рәисе Госман Исхакый да бар.

**Дамир Гайнетдинов язмасы,**
islam-today.ru сайтыннан тәрҗемә



# Үзеңнең изге икәнеңне белеп буламы?

Фото: elements.envato.com

**Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә берәр колын сөйсә, Җәбраил галәйһиссәламгә: «Мин фәлән кешене сөямен, син дә аны сөй», – дип әйтер. Җәбраил галәйһиссәлам күк әһелләренә: «Дөреслектә, сезнең Раббыгыз фәлән кешене сөя, сез дә аны сөегез», – дип әйтер. Ул колны күк әһелләре дә сөярләр. Аның өчен җирдә дә өстенлек куелыр. Аллаһы Тәгалә бер колына ачуланса да, моңа охшашлы булыр».**

Шәкыйкъ бине Ибраһимнән риваять ителә. Бер кеше аннан болай дип сораган: «Дөреслектә, кешеләр мине изге дип әйтәләр. Мин үземнең изге яисә изге түгел икәнлегемне ничек белә алам?» Шәкыйкъ бине Ибраһим аңа болай дип әйткән: «Салихлар (изгеләр) янында сереңне ач, әгәр ул эшеңә разый булсалар, син изгеләрдән булырсың, әмма разый булмасалар, үзеңне изге димә. Икенчесе – дөньяны күңелеңә сал. Әгәр аны күңелең кире какса, үзеңне салих дип бел. Өченчесе – нәфесеңә үлемне сал, ягъни исеңә төшер. Әгәр нәфесең үлемне тели икән, үзеңне салихлардан дип бел, әмма нәфесең каршы килсә, үзеңне изге дип белмә. Бу өч нәрсә синдә җыелса, гамәлеңә рия кермәсен өчен, Аллаһыга ялвар. Әгәр рия керә икән, гамәлләрең бозылыр».

### ГАМӘЛЛӘРГӘ РИЯ КЕРҮ

Әбү Бәкер Әл-Вәсәтый болай дип әйткән: «Итагатьне саклау – итагатьне кылудан авыррактыр, чөнки итагать пыяла кебек: тиз ватыла һәм кабат төзәтеп булмый. Гамәл рия өчен кылынган булса да, шулай булыр – рия гамәлләрне юкка чыгарыр. Әгәр берәү ниндидер эш эшләргә теләсә, ләкин риядан курыкса, ул рияны күңеленнән чыгарып, аннан арынуда тырышлык күрсәтергә тиеш. Ләкин моны эшли алмый икән, ягъни гамәлендә рия бар икән, ул эшне калдыру мәслихәттер. Аллаһыдан аның урынына гамәлендәге рия өчен ярлыкау сорар. Шаять, Аллаһы икенче гамәлен ихласлыкка ярашлы рәвештә кылуны насыйп итәр».

Мисал өчен әйтерләр: дөреслектә, дөнья рия кылучылар үлгәннән бирле харап булды, чөнки рия кылучылар кешеләр өчен файдалы булган – мосафирханәләр, күперләр һәм мәчетләр төзү кебек изге гамәлләрне рия белән эшли торган булдылар. Рия белән эшләнсә дә, мөселманнарның догасы бу гамәлне кылучыга еш файда бирер. Әүвәлгеләрдән риваять ителгәнчә, дөреслектә, мосафирханәне кылучы үз-үзенә: «Белмим, бу гамәлем Аллаһы Тәгалә өчен булдымы яисә юкмы?» – дип әйтә торган булды. Йоклаганда аңа мондый хәбәр ирешә: «Бу гамәлең Аллаһы Тәгалә өчен булмаса да, мөселманнар синең өчен дога кылалар, шуның өчен дә гамәлең Аллаһы Тәгалә өчендер».

### ФАРЫЗЛАРГА РИЯ КЕРӘМЕ?

Факыйһ радыяллаһу ганһе: «Фарызларны кешеләргә сөйлә», – дип әйткән. Кайберәүләр: «Фарызларга рия кермәс, чөнки ул гамәлләр барча халыкка фарыздыр. Аңа фарыз булган нәрсәне үтәсә, ул фарызга рия кермәс», – дип әйттеләр. Кайберәүләр: «Фарызларга да, фарызлардан башкага да рия керер», – дип әйткән.

Факыйһ радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Әгәр кеше фарызларны кешеләр күргәндә, йә кешеләр күрмәгәндә рия белән үтәсә, әлбәттә, фарызны үтәмәгән булыр. Мондый кеше тәмам икейөзледер. Ул Аллаһы Тәгалә әйткән кешеләр җөмләсеннән, ягъни икейөзлеләрдәндер:

> ***Һичшиксез, монафикълар – Утның иң түбән урынында. Син дә аларга бернинди ярдәмче таба алмассың».***
>
> *«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:145*

Әгәр икейөзлеләрнең Аллаһыны тануы дөрес һәм ихлас булса, рия ул кешене фарызларны үтәүдән тыя алмас иде. Әгәр кеше фарызларны халык янында күркәмрәк, тулырак итеп, ягъни тиешенчә үтәп, беркем күрмәгәндә, киресенчә, ким итеп үти икән, сәбәбы ким булыр. Ул кеше фарызлары өчен соралыр, алар белән хисап кылыныр.

Аллаһы Тәгалә белүчерәктер.

**«Тәнбиһүл гафилин»** китабыннан

# Замана кешесенә нәрсә җитми?

**Аллаһы Тәгалә Үзенең пәйгамбәрләре һәм китаплары аша хакыйкатьне һәм ялганны ачыктан-ачык күрсәткән, хәләлне һәм харамны билгеләгән. Раббыбыз кешене акыл белән бүләкләп, аңа сайлау иреге дә биргән. Коръәндә болай дип әйтелгән:**

> ***«Янә аңа ике юл күрсәтмәдекме?»***
>
> *«Әл-Бәләд / Шәһәр», 90:10*

Ике юл, ягъни берсе – дин юлы, икенчесе – динсезлек юлы. Кешедә булган начар һәм яхшы омтылышлар, сыйфатлар ике үзәккә барып тоташа дип аңлата ислам галимнәре. Аларның берсе – нәфес, икенчесе рух дип атала. Нәфес – ул кешенең асылы. Аның ярдәме белән тән төрле физик хәрәкәтләр башкара. Шулай ук, нәфес дип, кеше җанының тискәре сыйфатларын, теләкләрен дә атыйлар. Әгәр ул тәрбияләнмәсә, кешене гөнаһлы гамәлләргә китерергә мөмкин. Күрәсең, безнең борынгы бабайларыбыз әдәп-әхлак, хөрмәт төшенчәләрен дә дини мәгълүмат белән бергә алып барган. Рух дип кешенең җанын атыйлар. Аның турында кешегә бик аз мәгълүмат бирелгән. Аллаһы Тәгалә рух турында Коръәндә болай дип әйтә:

> ***«Алар синнән рух хакында сорыйлар. Әйт: «Рух – Раббымның** [«Бар бул!» дигән] **әмереннән. Сезгә исә гыйлемнән аз бер өлеш кенә бирелде».***
>
> *«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:85*

Рухның йогынтысы аркасында кеше игелекле гамәлләр кыла, Аллаһыга омтыла, Аңа мөрәҗәгать итә. Рух кеше үлеменнән соң да юкка чыкмый, аның аңлау, кабул итү сәләте дә кала.

Хәләлгә караганда харамны нәфес артыграк күрә. Нәфескә ярамаган, тыелган гамәлләр күбрәк ошый, күрәсең, шунлыктан ул кешеләрне үзе артыннан ияртә дә. Нәфес җиңел булган эшләргә омтыла, аңа ләззәт китерә торган гамәлләр, уеннар бигрәк тә ошый, диелә. Дин галимнәре хәтта кеше бик югары рухи дәрәҗәләргә ирешсә дә, үзенең нәфесе белән гомере буе көрәшә, дип аңлата. Ирексездән сорау туа: ә без, хәзерге заман кешеләре, нәфесебез белән көрәшәбезме соң? Юк шул, җәмәгать. Кайвакыт концертларга, театрларга, очрашуларга барасың да, торып чыгып китәсе килгән чаклар күп була. Совет чорында да әдәп-әхлак, тәртип, хөрмәт безнең тормышыбыз белән үрелеп барып, беренче урында булдылар. Сәхнәгә ярымшәрә чыгу гадәте бөтенләй юк иде. Укытучыларыбызга рәхмәт, балаларны сәхнәгә чыгар алдыннан күкрәгендәге сәдәфләргә кадәр тикшерерләр иде, төймәләнмәгәнен төймәләрләр иде. Чәчләренең үрелгән булуына да игътибар итәрләр иде. Хәзерге вакытта олысына-кечесенә карарга оят, барысы да – башка милләтчә: кем ничек чишенә алган, тәннәре ярым-ярты ачык. Кайсыберләре белән очрашып, сөйләшеп, аңлатып та карыйм. «Безгә өстән кушалар», – дигән җавап та ишеткән бар. Кеше ышанмаслык ялган бу! Әгәр син үзеңне татар милләтеннән дип хис итәсең икән, шулай әйтүчегә исбатла, аңлат, сәхнәгә әдәпсез чыгарга миңа оят, 1000 елдан артык тарихы булган милләтемне хөрмәт итәм, ата-ана тәрбиясенә тап төшерәсем килми, дип әйт. Әдәплелекнең ничек булуын үз үрнәгеңдә күрсәт. Тамашачыга булган хөрмәтеңне җиткер! Тамашачы кичәгә үзенә нинди булса да бер уңай фикер, тәрбия, гыйбрәтле нәтиҗә алып кайту өчен килә. Безнең чорда яшәгәннәр моны бик яхшы хәтерли. Ничек сөйли, ничек атлый, нәрсә яхшы, нәрсә начар, үз тормышында кайсысын куллана аласың, үзеңдә андый җитешсезлекләр юкмы – театрдан я концерттан кайткач, 4-5 кыз шулар турында сөйләшә, фикер алыша идек. Ә хәзер исә: «Сеңлем, сезгә ошадымы? Нинди фикерләр белән кайтасыз?» – дип сорагач, «Әллә тагын, белмим», – дип җавап кайтаралар. Димәк, тамашаның тәрбияви тәэсире булмаган. Кул чабу әле ул барлык тамашачыга да 100 процент ошаганын, куелган әсәрнең яхшы булганын аңлатмый. Кайбер вакытта кул чабучы ханымнарга: «Кайсы ягы ошады?» – дип сорау бирәм. Җавапка: «Берсе дә ошамады», – дигән сүзләр ишетәм. «Алай булгач, нигә кул чаптыгыз соң?» – дип сорыйм сәерсенеп. «Кеше чаба, мин дә алардан калышмыйм, йоклаган димәсеннәр», – ди.

Концерттан, театрдан кайткач, төннәр буе йоклый алмый уйланам: «Хәзерге вакытта безгә нәрсә җитми? Нәрсәне күздә тотарга? Халык белән ничек эшләргә?» Бу сораулар бербер артлы күңелне тырный. Мондый вакытларда мин һәрвакыт тарихка күз салам. Безнең татар милләте ничегрәк булган? Гомер-гомергә билгеле, әдәпле, сабыр, үткен фикер йөртүче, аек акыллы, хезмәт сөюче, ярдәмчел, алга омтылучы, кыскасы, яхшы белән начарны аера белүче, гадел хөкем итүче, оят, хөрмәт төшенчәләрен яхшы белүче милләт вәкилләре булган ата-бабаларыбыз. Ярар, шанлы вакытлар үтеп, данлы үткәннәре генә калды, ди. Хәзер нәрсә эшли алабыз соң? Минемчә, һәркем үзеннән башлый. Очрашу урыннарында, радио-телевидениедә, мәдәният йортларында, мәктәпләрдә укытучыларның вакыты ничек кенә тыгыз булмасын, әдәп-тәртип, әхлак-хөрмәт кагыйдәләрен өйрәтергә тиеш дип саныйм. Дингә барып җиткәнче, адәм баласы күкрәген, кендеген, билдән түбән әгъзаларын, күлмәк итәген ярым күрсәтеп, ачып, селкетеп биюдән, үкерүдән, төрле әдәпсезлектән арынырга тиеш. Җырчыларыбызның үрнәк булырлык концертлары да бар. Җырларның эчтәлеге буенча да, тамашачы белән элемтәдә барган мәгънәле, халыкка мәгълүмат бирә алыр дәрәҗәдәге концертлар да бар, әмма алар бик аз.

Бәлки безгә түбәндәгечә эшләп карарга́дыр?! Халыкка, иң беренче, аралашу кирәк. Бу безнең милләтнең канына сеңгән. Театр, концерт башланганчы, язучылар (алар элек бик актив иде), шагыйрьләр, имамабыстайларның җыелы, тәрбияви чыгышларын оештырырга кирәктер, минемчә. Халык хәзерге тарихчыларның хезмәтләрен белми дә яши бит. Кайда алар, алар белән ничек аралашырга? <...>

Нигә без хәзер генә ваемсызланып яши башладык? Өстебез бөтен, тамагыбыз тук, өстәлебездә – икмәк, әлхәмдүлилләһ, тынычлыгыбыз бар. Гади генә нәрсәләрдә милләтебезгә тап төшерәбез. Башка милләт артыннан барып, үз дәрәҗәбезне, оят-хөрмәтебезне югалтырга ирек куябыз. Бу безнең барыбызга да кагыла...

**Сәйдә абыстай Аппакованың**
«Тузмас бүләк» китабыннан

# Сөннәтче бабай


Фото: shutterstock.com

*(Дәвамы. Башы алдагы санда)*

Хәзрәт, тәһарәт алып, кан алу хакындагы хәдисләрне укып, салават әйтеп, килеп утыра иде. Сөннәтче бабай, тагы бисмилла әйтеп, салават әйтеп, хәзрәтнең арт чигәсен бик йомшак кына иттереп кыра иде дә, тагы бер салават, тагы бер бисмилла әйтеп, пәкесенең очы берлән чиртергә тотына иде. Каннар агып, хәзрәтнең муенына төшә башлагач, ул, мөгезне куеп, аның башындагы тишегеннән һаваны суыра да, шуның тишегенә ябар өчен бәйләтелгән сарык имчәкен юешләтеп, тишекне ябып куя иде дә, икенче чигәгә чиртергә тотына, аны да шул юл берлән эшләп, мөгез утырта да, шунларның тулганын көтеп тора иде. Шул вакытта хәзрәт Сөннәтче бабайдан элгәреге заман хәзрәтләре хакында сораша; ул да элгәреге Кәбир хәзрәт, Сафа хәзрәтләрнең кан алдырулары хакында, бер мәртәбә тәбәрәк Кәбир хәзрәтнең кан алдыргач һушы китү кыйссасын, шуннан абыстай мәрхүмәнең хәзрәтенә кан алырга рөхсәт бирмәвен сөйли иде. Һәрвакыт шул хәбәр сөйләнеп бетүгә мөгезләр кан берлән тула иде дә, тагы бисмилла, салават әйтеп, Сөннәтче бабай, мөгезләрен акыртын гына алып, әүвәлдән хәзерләнгән савытка сала да, катык кеби каткан кара канга карап: «Сөбханалла, хәзрәт, күз тимәсен, каныңыз бик бозылган, кап-кара!» – дия иде. Сөннәтче бабай тагы мөгезне утыртыр өчен урынын карый, теге, җәрәхәтләрнең кайсыберсе бетәшкән булса, тагы чалгы пычагының очы берлән аркылы-торкылы чиртә иде дә, тагы мөгезне утырта, тагы иске заман кешеләре хакында сүзгә керешә иде. Монысында да кан кара чыкса, Сөннәтче бабай: «Машалла, хәзрәт!» – дип, тагы хәзрәтнең канының бозылуы хакында сөйли, хәзрәт тә, шул бозык канны чыгарып бетерер өчен, тамырдан кан алдырырга уйлый башлый, ләкин һәрвакыт шул мәсьәләгә килгәч: «Мөгез салдыру сөннәт булса да, кан алдыру бидгать (ярамый торган эш-гамәл – **ред.**) түгелме?» – дип, пәйгамбәребезнең кан алдыруы хакында ачык ривайәт күргәне юкка, шөбһәләнеп, торып, шүрлектән китап алып, китап карарга тотына, шуның хакында ривайәт тапканча маташып, шуннан соң гына разый була иде. Сөннәтче бабай, сул яки уң кулының терсәкен бөкли торган җиреннән кара тамырын табып, тагы: «Бисмилла!» – дип, салават әйтеп, балтасы берлән чаба, кан чәчрәп чыгып, фонтан булып түшәмгә таба ата башлагач та, җиз тазга хәзрәтнең кулын бора, үзе тагы, чыккан бер канның суынып-каралып катканын күргән саен: «Машалла, машалла, хәзрәт, каның бик бозылган икән, кап-кара!» – дип, хәзрәткә сөйли; хәзрәт, шул бозылган каннан котылыр өчен, һаман агыздыргаННан-агыздыра бара иде. Гадәттә ике-өч чүмеч кадәр агызсалар да, кайсы елларны хәзрәтнең каны бик бозылып киткәнгә, күбрәк тә агызалар, агарга куйган җиз таз тулгач кына тамырны ныклап бәйләп туктаталар иде. Шуннан соң хәзрәт юынырга тотына, Сөннәтче бабай каннарны күтәреп чыгып, мәхшәр көнне азып-тузып, ияләрен эзләп йөрмәсеннәр өчен, һәр елны күмелә торган, бала-чага маташмый торган почмакка чокыр казый иде дә, салават әйтеп күмә иде. Шуннан соң абыстай хәзерләгән самовар янында чәй эчәләр иде. Сөннәтче бабай хәзрәткә канны йомшартыр өчен пешкән коймак ашарга, канны сыеклатыр өчен лимән берлән чәй эчәргә мәслихәт итә иде. Замана башка булганга, халык ул вакыт таза булганга, хәзрәткә шул кан алдыру начар тәэсир итми иде. Ләкин күп вакытта шул кан алу аңар әллә нинди файдалы булып, җиңеләйтеп тә җибәрми иде. Әүвәл көннәрне бераз башы әйләнеп йөрсә дә, ул бик тиз элгәреге хәленә керә, аз гына да куәте кимегәнен сизми иде. Кан алганнан соң һушы китеп егылулар-фәләннәр хәзрәт берлән һич булмый иде. Чәйдән соң Сөннәтче бабай, дога кылып торып, чәйгә рәхмәт укый, хәзрәт тә, мәшәкатьләнүенә рәхмәт укып, Сөннәтче бабайга бирәр бүләк бирә иде. Сөннәтче бабайның мәшәкатьләнүе «бә ризаи аллаһе тәгалә» булган кеби, хәзрәтнең дә бирүе «бә ризаи аллаһе тәгалә» иде. Бу бирүләр, алулар, хәзерге, безнең замандагы кеби, докторга, яисә акушеркага бирү кеби, эш хакы түләү түгел, бүләк бирү иде. Шуның өчен күп вакыт хәзрәт Сөннәтче бабайга акча бирмәенчә, йә бер-ике генә юган күлмәк бирә, яисә моннан дүрт кенә ел элек алынган читеген тоттыра, яисә Әхмәди хаҗи бүләк иттереп хаҗ мөбарәктән алып кайткан мисвәк (теш чистарту өчен махсус таякчык – ред.) шәрифне бирә иде. Сөннәтче бабай боларның һәммәсен дә бик зур разыйлык берлән алса да, мисвәк шәрифкә аның кәефе тагы күбрәк килә иде. Ул аны Гөлйөзем әбигә кайтып мактаткан кеби, бик саклап кына тота, аны мич янындагы иң кадерле җиргә куя иде.

Сөннәтче бабайның бу бәйрәме дә үтеп китә, ул тагы иске киемнәрне киеп, иске тормыш берлән яши башлый иде. Ул вакытта җәдиде-кадиме, гәзите-мәзите, думасы-бумасы юк; ул вакытта мәктәп, мәдрәсә мәсьәләсе, тел мәсьәләсе, муллалар, яшьләр мәсьәләсе юк иде. Һәр мәсьәлә хәл кылынган, һәр агымга юл билгеләнгән иде. Һәр кешенең вазыйфасы бер-берсеннән аерылган иде. Яңа эш, яңа хәбәр юк иде. Аның юклыгы да хис ителми, аның кирәклеге дә сизелми иде. Тормыш һәммә җирдә бер форма алган, шул формасыннан бара, шул алган кителшендә, җәйге җилсез көнне ашъяулык кеби, тип-тигез ага торган Идел кеби ага иде. Аңар каршы торган буа юк, аның агымын тирескә сөрергә теләгән һавалы җил дә юк иде. Тын иде, тыныч иде; тынычлыкның очы юк иде.

*(Дәвамы киләсе санда)*

**Гаяз Исхакый**

## ДҮШӘМБЕ, ЧӘРШӘМБЕ, ҖОМГА

**07.00** «Минбар»
**07.20** «Хәерле сәгатьтә»
**08.10, 17.00** «Онлайн мәдрәсә»
**08.30, 17.30** «Хаҗ кылырга өйрәник»
**08.40, 17.40** «Рамазанга табиб киңәшләре»
**08.45, 17.45** «1001 хәзинә»
**8.55, 17.55** «Тәфсир». Тимергали Юлдашев
**9.15, 18.15** «Фикер»
**10.00, 19.00** «Әлифба. Коръән уку сабаклары»
**10.20, 19.20** «Коръән могҗизалары»
**10.30, 19.30** «Дин турында»
**11.00, 20.00** «Билал»
**11.30** «Минем Рамазан»
**11.40, 20.40** «Намазга өйрәник» (хатын-кызлар өчен)
**12.00** Азан
**12.05, 21.00** «Чудеса сотворения»
**12.15, 21.10** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым»
**12.25, 21.20** «Онлайн медресе»
**12.55, 21.50** «Знамения Корана в свете современной науки»
**13.05, 22.00** «Узнаем у имама»
**13.50** «Актуальные вопросы о Рамадане»
**13.55, 22.50** «Алифба»
**14.10** «Есть вопрос – есть хадис»
**14.20** Документальные фильмы
**14.50** «Тайна»
**15.05** «Халяль-лайфстайл»
**15.20** «Мой Рамадан»
**15.25** «Пока не наступил Рамадан»
**15.35** «Голос разума»
**16.05** «История ислама в России»
**16.25** «Ислам сегодня»
**20.30** «Минем Рамазан»
**22.45** «Рухуль Байан»
**23.10** «Актуальный Ислам»
**23.25** Документальные фильмы
**00.55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод

## СИШӘМБЕ, ПӘНҖЕШӘМБЕ ШИМБӘ

**07.00** «Минбар»
**07.30** «Хәерле сәгатьтә»
**08.20, 17.20** «Җан авазы»
**08.30, 17.30** «Хаҗ кылырга өйрәник»
**08.40, 17.40** «Шифалы Рамазан»
**08.50** «Сабыйлар остаханәсе»
**09.05, 18.05** «Фарыз ураза»
**09.10, 18.10** «Татарлар тарихы»
**09.50, 18.50** «Тәмле булсын»
**10.05, 19.05** «Имамнан сорыйк»
**10.50, 19.50** «Рисалә. Габделкаюм Насыйри»
**11.00, 20.00** «Билал»
**11.30, 20.30** «Бер хәдис – бер җавап»
**11.40, 20.40** «Намазга өйрәник» (ир-атлар өчен)
**12.00** Азан
**12.05, 21.00** «Азбука Ислама»
**12.25, 21.20** «Онлайн медресе»
**12.55, 21.50** «Дети в саду пророчества»
**13.10, 22.05** «40 хадисов 40 толкований»
**13.40, 22.35** «Узнаем у имама»
**14.25, 23.30** «Халид бин Валид»
**15.15** «Познай свою религию»
**15.30, 00.20** «Ислам сегодня»
**16.05** «Рамазан»
**16.10** Документальные фильмы
**16.40** «Вера в предопределение»
**16.45** «Хафтияк Шариф»
**16.55** «Советы на Рамадан»
**17.00** «Мәслихәт»
**17.50** «Сабыйлар остаханәсе»
**23.20** «Продуктивный Рамадан»
**00.55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод

## ЯКШӘМБЕ

**07.00** «Минбар»
**07.30** «Шифа»
**08.00, 12.35** «Билал»
**09.50, 19.20** «Дин турында»
**10.20** «Мәслихәт»
**10.40, 19.50** «Әхлак сабаклары»
**10.45** «Имамнан сорыйк»
**11.30** Фильм: «Шиһабетдин Мәрҗани»
**12.00** Азан
**12.05** «Онлайн медресе»
**12.25, 21.20** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым»
**14.25, 23.50** «Узнаем у имама»
**15.10, 00.35** «Познай свою религию»
**15.25** Документальные фильмы
**15.55** Конкурс чтецов Корана
**16.30** Короткометражный фильм
**16.50** «Пока не наступил Рамадан»
**17.00** «Онлайн мәдрәсә»
**17.20** «Тәфсир». Тимергали Юлдашев
**17.40** «Күңелдән күңелгә»
**17.50** «Мәүлид – 2022» (кабатлау)
**18.20** «Татарлар тарихы»
**19.00** «Хикмәтле хикәяләр»
**19.10** «Бер хәдис – бер җавап»
**19.55** Фильм: «ТР МДН – 30 ел»
**20.25** «Тәфсир»
**21.00** «Онлайн медресе»
**21.30** «Ислам сегодня»
**22.00** Конкурс чтецов Корана
**22.25** «Тайна»
**22.50** «Архитектура частной жизни»
**00.50** «Следовать сунне – это...»
**00.55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод

**ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ**

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**

Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе **Камил СӘМИГУЛЛИН;**

«Хозур» нәшрият йорты директоры **Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;

ТР МДНнең Шәригать бүлеге җитәкчесе **Булат МӨБАРӘКОВ;**

Татарстанның баш казые **Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**

ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы **Габдулла ӘДҺӘМОВ**

Баш мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Мөхәррирләр: **Юлдашева А. И., Ситдикова Г.Р.**
Логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Шәйхетдинов А. Х.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** izdat@huzur.ru

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**НӘШИР:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт).
Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.

Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.

Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә. Заказ №2587.
График буенча – 27 нче март 21.00, гамәлдә – 21.00 сәгатьтә кул куелды.

Газетага ярты елга язылу бәясе – 168,90 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 29 нчы март көнне таратыла.

# НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

## АПРЕЛЬ 2023 / КАЗАН

| Көн | Көн исеме | ИРТӘНГЕ НАМАЗ | | Кояш чыга | ЗӘВӘЛ | ӨЙЛӘ НАМАЗЫ | ИКЕНДЕ НАМАЗЫ | АХШАМ НАМАЗЫ / ИФТАР | ЯСТУ НАМАЗЫ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | | |
| 01 | Шим | 03:01 | 03:45 | 05:15 | 11:47 | 12:00 | 16:11 | 18:20 | 20:09 |
| 02 | Якш | 02:58 | 03:42 | 05:12 | 11:47 | 12:00 | 16:13 | 18:22 | 20:11 |
| 03 | Дүш | 02:54 | 03:40 | 05:10 | 11:46 | 12:00 | 16:14 | 18:24 | 20:14 |
| 04 | Сиш | 02:50 | 03:37 | 05:07 | 11:46 | 12:00 | 16:15 | 18:26 | 20:17 |
| 05 | Чәрш | 02:47 | 03:35 | 05:05 | 11:46 | 12:00 | 16:17 | 18:28 | 20:19 |
| 06 | Пәнҗ | 02:43 | 03:32 | 05:02 | 11:46 | 12:00 | 16:18 | 18:30 | 20:22 |
| 07 | Җом | 02:40 | 03:29 | 04:59 | 11:45 | 12:00 | 16:20 | 18:32 | 20:25 |
| 08 | Шим | 02:36 | 03:27 | 04:57 | 11:45 | 12:00 | 16:21 | 18:34 | 20:28 |
| 09 | Якш | 02:32 | 03:24 | 04:54 | 11:45 | 12:00 | 16:23 | 18:36 | 20:30 |
| 10 | Дүш | 02:28 | 03:22 | 04:52 | 11:44 | 12:00 | 16:24 | 18:38 | 20:33 |
| 11 | Сиш | 02:25 | 03:19 | 04:49 | 11:44 | 12:00 | 16:26 | 18:40 | 20:36 |
| 12 | Чәрш | 02:21 | 03:17 | 04:47 | 11:44 | 12:00 | 16:27 | 18:42 | 20:39 |
| 13 | Пәнҗ | 02:17 | 03:14 | 04:44 | 11:44 | 12:00 | 16:28 | 18:44 | 20:42 |
| 14 | Җом | 02:13 | 03:12 | 04:42 | 11:43 | 12:00 | 16:30 | 18:46 | 20:45 |
| 15 | Шим | 02:09 | 03:09 | 04:39 | 11:43 | 12:00 | 16:31 | 18:48 | 20:48 |
| 16 | Якш | 02:04 | 03:07 | 04:37 | 11:43 | 12:00 | 16:32 | 18:51 | 20:51 |
| 17 | Дүш | 02:00 | 03:04 | 04:34 | 11:43 | 12:00 | 16:34 | 18:53 | 20:54 |
| 18 | Сиш | 01:56 | 03:02 | 04:32 | 11:42 | 12:00 | 16:35 | 18:55 | 20:58 |
| 19 | Чәрш | 01:51 | 02:59 | 04:29 | 11:42 | 12:00 | 16:36 | 18:57 | 21:01 |
| 20 | Пәнҗ | 01:47 | 02:57 | 04:27 | 11:42 | 12:00 | 16:38 | 18:59 | 21:04 |
| 21 | Җом | 01:42 | 02:54 | 04:24 | 11:42 | 12:00 | 16:39 | 19:01 | 21:07 |
| 22 | Шим | 01:38 | 02:52 | 04:22 | 11:42 | 12:00 | 16:40 | 19:03 | 21:11 |
| 23 | Якш | 01:33 | 02:49 | 04:19 | 11:41 | 12:00 | 16:42 | 19:05 | 21:14 |
| 24 | Дүш | 01:28 | 02:47 | 04:17 | 11:41 | 12:00 | 16:43 | 19:07 | 21:18 |
| 25 | Сиш | 01:22 | 02:45 | 04:15 | 11:41 | 12:00 | 16:44 | 19:09 | 21:21 |
| 26 | Чәрш | 01:17 | 02:42 | 04:12 | 11:41 | 12:00 | 16:46 | 19:11 | 21:25 |
| 27 | Пәнҗ | 01:11 | 02:40 | 04:10 | 11:41 | 12:00 | 16:47 | 19:13 | 21:29 |
| 28 | Җом | 01:05 | 02:38 | 04:08 | 11:41 | 12:00 | 16:48 | 19:15 | 21:33 |
| 29 | Шим | 00:59 | 02:35 | 04:05 | 11:40 | 12:00 | 16:49 | 19:17 | 21:36 |
| 30 | Якш | 00:53 | 02:33 | 04:03 | 11:40 | 12:00 | 16:51 | 19:19 | 21:40 |

**21 нче апрель – 1 шәүвәл – Ураза бәйрәме**